КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 декабрь г.Казань № 1013

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының» 2006 ел, 24 март, 127 нче карары белән расланган Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә алар түләгән иминият премиясе компенсациясен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына керә торган субвенцияләр исәбеннән транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәсе буенча иминият премияләре компенсациясен түләү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә алар түләгән иминият премиясе компенсациясен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына керә торган субвенцияләр исәбеннән транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәсе буенча иминият премияләре компенсациясен түләү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 24 март, 127 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 7 октябрь, 736 нчы; 2010 ел, 25 июнь, 510 нчы; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2016 ел, 27 октябрь, 791 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул

исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә алар түләгән иминият премиясе компенсациясен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына керә торган субвенцияләр исәбеннән транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәсе буенча иминият премияләре компенсациясен түләү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Компенсация инвалидның (инвалид баланың) яшәү урыны буенча «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең бүлекләре (алга таба – Үзәк бүлеге) тарафыннан билгеләнә.»;

6 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Компенсация билгеләү турында гариза инвалид яки инвалидның яисә инвалид баланың законлы вәкиле тарафыннан (алга таба – гариза бирүче) инвалидның (инвалид баланың) яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә бирелә.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) милекчесе сыйфатында инвалид (инвалид бала) яки инвалид баланың законлы вәкиле күрсәтелгән транспорт чарасы паспорты күчермәсе;»;

җиденче абзацта «муниципаль берәмлекләрдә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органнары» сүзләрен «Үзәк бүлекләре» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «муниципаль берәмлекләрдә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органнары» сүзләрен «Үзәк бүлекләре» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «муниципаль берәмлекләрдә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органнары» сүзләрен «Үзәк бүлекләре» сүзләренә алмаштырырга;

9 нчы пунктның икенче абзацында «муниципаль берәмлекләрдә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы территориаль органының» сүзләрен «Үзәк бүлекләре» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин